…ЯЛТ ИТТЕР КҮҢЕЛЕҢНЕ СЫЗЫП АК НУР БЕЛӘН!

# Караш

1999 нчы елның 19 нчы маеннан чыга.
№ 9 2017. ИЮНЬ
«НӘШРИЯТ ЭШЕ» түгәрәге

## ТИЗРӘК! БИЕГРӘК! КӨЧЛЕРӘК!

## Чирмешән районында үтүче җәйге ГТО фестивале уңаеннан махсус чыгарылыш №2

**Районыбызда өч көн буена ГТОчылар ярышты, хезмәткә һәм оборонага әзерлекләрен күрсәтте. Илкүләм җәйге фестивальнең республика этабына узган 13 район вәкилләре - 100дән артык мәктәп укучысы җиңел атлетика, йөзү, пневматик мылтыктан ату һәм башка спорт төрләрендә көч сынашты.**

**1 нче көн. 9 нчы июнь. Ничә көннәр буена йөзен күрсәтмәгән кояш бүген иртәдән үк балкый. Сәбәбе дә бар шул: Илкүләм җәйге фестивальнең республика этабы** башланды. Дулкынландыргыч мизгелләр. Республиканың шәһәр һәм районнарыннан - Әлмәттән, Түбән Камадан, Яр Чаллыдан, Казаннан, Бөгелмәдән, Зәйдән, Азнакайдан, Сабадан, Спастан, Лениногорскидан, Мамадыштан, Мөслимнән һәм Чирмешәннән сигезәр кешелек командалар, 11-15 яшьлек кызлар, егетләр арасындагы ярышлар иртәдән үк башланды. Винтовкадан ату буенча ярышлар Чирмешән лицее спорт залында башланды. Яшь ГТОчылар төзлекне тикшерүдәге спорт төрендә сынатмадылар. “Тренировкаларда яхшырак нәтиҗә иде, бераз каушадым “, - диде командабыз члены Русинә.





15 сәгатьтә “Чирмешән” физкультура-савыктыру комплексында узган фестивальне ачу тантанасында районыбыз үзенең кунакларны каршылый алу сәләтен күрсәтте. Килгән кунаклар да бик канәгать калды. 16 сәгатьтән стадионда җиңел атлетиканың көч сынашу башланды:ераклыкка сикерү, туп ату, 60 метрлы, 1500, 2000 метрлы дистанцияләргә йөгерү. Барыбыз да бик тырышты. Авыр булды дип әйтә алмыйм, тренировкалар үзенекен эшләде, чын йөрәк белән беренчелеккә омтылу, остазларыбыз йөзенә кызыллык китермәскә тырышу үзенекен итте: нәтиҗәләр начар түгел. Әлегә протоколларны күрмәсәм дә, шулай икәнлеген сизәм, чөнки дистанөияләрдәге тизлек, бер-беребез өчен җан ату моңа ишарә булды.. Алда тагы ике көн...

***Икенче көн. 10 нчы июнь. Уянуга (Йокладыммы икән әле мин? Кичәге дулкынландыргыч мизгелләрне, кайткач та кат-кат күңелемнән кичереп ята торгач, йокы тәмам качты. Югыйсә, арылган булырга тиеш бит инде) тәрәзәгә карадым, анда кабат кояш көлә. Димәк, көн матур, бу үзе яхшы фал түгелме соң ? Бүген безне тестлар эшләү ( ГТОчы белемле булырга тиеш!), многоборье ( бусы үзе гаҗәп чыдамлыкны көчне сыный: яткан килеш гәүдәне күтәреп төшерү – отжимание, поднимание и опускание туловища- без аны пресс дибез инде, турникта тартылу), йөзү...***

***Минем иң яраткан спорт төрем – йөзү дип бер әйттем бугай. Чыннан да, йөзү – минем стихия. Мәктәбебездә бассейн булу безнең өчен зур бәхет. Шуңа да бүгенге мәктәбебез базасында уздырылган йөзү ярышы командабызга авырлык тудырды дип әйтә алмыйм. Без инде үзебезне судагы балыклар кебек хис иттек дисәк тә ялгыш булмас. Ни генә дисәң дә, өйдәге стеналар да булыша бит.***



***Бу – безнең КОМАНДА. Командада эшли алу, дуслык, бердәмлек, бер-берең өчен җан ату, борчылу, сөенә алу – иң зур биеклек. Спорттагы физик мөмкинлекне билгеләүче түгел, ә Кеше булуны билгеләүче фактор.***





*Дулкынландыргыч көтү мизгелләре...*

***Физик әзерлек ул көчле булу гына түгел. Ул сәламәт тән, сәламәт акыл, матурлык та бит . Яшьтәшләремә үзебезнең фестиваль күренешләреннән шуны җиткерәсем килә: буш вакытыгызны сәламәтлеккә багышлагыз. ГТО значогы матур күкрәк бизәге генә түгел, ул синең рухыңның ныклыгын күрсәтә.***



***Тагын! Тагын! Тагын!***

**Фестивальдә иң кыены кемгә дип уйлыйсыз? Катнашучыларгамы? Юк! Без җиңүгә булган омтылышыбыз белән бергә бер кыенлыкны да сизмибез. Иң кыены судьяларга. Нинди зур җаваплылык: һәр секундны дөрес билгеләргә, хәтта секунд өлешләре дә зур роль уйный бит монда. Әмма безнекеләр молодец! Шуңа да безнекеләр бит инде алар!**



**Иң мөһиме онытылып кала язган: ярышларны оештыру дәрәҗәсе белән генә түгел, тәмле сыйларыбыз белән дә кунаклар алдында йөзебез ак безнең.**

***Бүгенгә менә шул. Иртәгә соңгы көн. Бездәге ярышларда ачыкланачак иң көчле спортчылардан республика командасы тупланырга тиеш. Димәк, ирешәсе биеклекнең чиге юк. 11 енче июндә безне презентация һәм эстафета көтә. Аннары... Аннары ҖИҢҮЧЕЛӘР билгеле булачак. Хәер, без барыбыз да ҖИҢҮЧЕ. ИҢ-ИҢнәре гадел ачыклансын, республика командасына иң лаеклылары узсын!!!***




**"Караш" газетасының әлеге саны өчен җаваплы: Сафиуллина З. А.**
**Хәбәрләшү өчен телефон: 9274825605**